# СҮЗ БАШЫ

Мин балачактан Каюм Насыйриның «Әбүгалисина» әсәре белән «җенләнеп» үстем. Җиде-сигез яшьләрдә булдым микән, Зәй районының Югары Шепкә авылы клубында укытучы әнием Гөлҗәннәт белән (әтиебез хәрби очучы, 1945 елның февраль аенда, Венгрияне азат иткәндә, хәбәрсез югала) Казаннан килгән филармония артистлары концертында күз буучыны күреп шаккаткан идем. Хәй ага Мушинский булган икән ул. Үсеп җитеп, артист-иллюзионист булып эшли башлармын да Хәй аганың көндәшенә әйләнермен дип уема да килми иде.

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшли башлаганда, эстрада бригадаларында өч иллюзионист бар иде: Хәй Мушинский, Рәмзи Гарифуллин, Полина Половникова. Милли сәнгатебездә Советлар чорына кадәр ул жанрны яхшы белүче, башкаручы артистлар булмаган дисәм ялгышмам. Дөрес, циркта көрәшче Кара Әхмәт булуы турында бөек шагыйребез Габдулла Тукай үзенең «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасында язып калдыра.

1959 елда, иллюзия сәнгате дөньясында зур тавыш чыгарып, иллюзия остасы Али Вадның (Александр Вадимовның) «Искусство фокуса», «Фокус на клубной сцене», «Фокусы для всех» һәм иллюзия сәнгатенең тарихын «От магов древности до иллюзионистов наших дней» дигән китаплары бер-бер артлы басылып чыкты. Аңа ияреп, Мәскәү филармониясе иллюзионисты Арутюн Акопян да «Фокусы на эстраде» дигән китабын бастырды. Фокус сөючеләр һәм шулай ук эстрадада эшләүче яшь иллюзионистлар өчен бу китаплар өстәл китабына әверелде.

Уналты яшьтән үк Пермь өлкәсенең Закамский шәһәрендә хәрби заводта хезмәт кую, Урта Азиядә «бәхет эзләп» ачлы-туклы дөнья күрү, армия хезмәте, институтта уку, филармониядә артист-иллюзионист булып эшләү, цирк артисты, Казан циркының баш режиссёры булып утыз ел эшләгән чорлар артта, кире әйләнеп кайтмаслык булып, томан эчендә калган.

Менә инде тормышта күргәннәрне, узганнарны сагынып, искә алу чорына килеп тә җиткәнмен. Уртаклашасы серләрем бар: шушы китапта иллюзия (күз алдау) сәнгатенең серләрен ачасым килә.

## Сүз башы

**«Иллюзия – күз алдау – «күз буу» тарихы белән танышыйк.** Тарихчылар күз буу сәнгате Мисырда туган дип саныйлар. Безнең эрага кадәр биш мең еллар элек үк Чатча-Эм-Анк дигән тылсымчы Хуфу фиргавенне үзенең чыгышы белән гаҗәпләндергән. Сәнгать тарихчылары, папирусларда сурәтләнгән «могҗизалар» бүгенге күз буучыларның номерларын хәтерләтә, дип язалар.

Борынгы Мисыр, Халдей, Бабил, Грециядә җир асты мәгарәләренең серле бүлмәләрендә ул «могҗизалар»ның серләре саклаган. Дин әһелләре ул серләрне, күз карасы кебек саклап, буыннан-буынга гына тапшыра торган булганнар. Тылсым гыйлеменә ия булу аларга үзләрен Аллага якын кешеләр итеп күрсәтү өчен кирәк булган.

Ул чорда зур акыл, тапкырлык белән эшләгән механизмнар гыйбадәтханәләрдә гади халык өчен, чынлап та, могҗизалар күрсәткән: Алла сыны күз алдында җанланган, алтарьларда үзлегеннән «изге утлар» кабынган. Таш сыннар динне мактап «елаганнар».

Фокус – күңелле шаяру гына түгел, катлаулы башваткыч та. Шуңа күрә фокусчы иҗади булырга, механиканы, физиканы, химияне белергә тиеш. Артист өчен кулларның, бармакларның җитезлеге, сәхнәдә үзен тотышы да кирәкле сыйфатлар.

Фокусчылар ике төркемгә бүленә: күз буучы һәм манипуляторга.

Күз буучы үзенең чыгышында күптөрле катлаулы аппаратлар, механизмнар кулланса, манипулятор үзенең хәрәкәтчән оста бармакларына, кул чукларына таяна.

Манипуляция – катлаулы кул хәрәкәтләре ясап, оста итеп фокус күрсәтү. Манипуляция – күз буу сәнгатенең «әлифбасы». Гәүдәнең, кул чукларының нәфис хәрәкәтләнүе, башның борылуы, күзнең сизелер-сизелмәс кенә уйнавы артист-манипулятор чыгышында бик әһәмиятле.

Күп очракта фокусчы, манипуляция белән күз бууны кушып, программасын баета, осталыгын арттыра, профессиональ яктан үсә. Ялкау артист-иллюзионистлар да очрый, алар, манипуляцияне кире кагып, үзләренең чыгышларын ярлыландыралар, программаларында катлаулы зур аппаратлар, механизмнар кулланалар. Циркта еш кына манеж астына төшү өчен люклар, төрле җайланмалар ярдәмендә, «юк булу», «пәйда булу» кебек трюкларны ясыйлар.

Бу очракта инде күз буу сәнгате гади генә машиналар хәрәкәтенә кайтып кала: бөтен эшне ассистентлары башкарып, артист – күзәтүче генә булып чыгыш ясый.

Манипуляция – күз буу сәнгате – балет станогы янында кул, аяк, гәүдә хәрәкәтләре ясауны таләп итә. Кулларның җитезлеге, осталыгы тамашачыларны һәрвакыт гаҗәпләндерә. Фокусчының бармаклары, пианист, баянчыларның бармаклары кебек оста хәрәкәтләнеп, чыгыш ясаганда, уңышларга ирешергә ярдәм итә.

Бу китапны укып чыктым да фокусчы булдым дигән сүз түгел. Оста күз буучы булу өчен, манипуляция техникасын-кагыйдәсен яхшы үзләштереп, шактый репетицияләр ясарга, тир түгәргә кирәк.

Мин чыгышларымда, манипуляция белән күз бууны катнаштырып, бербөтен тамаша ясыйм. Кайсы күз буу, кайсы манипуляция икәнен тамашачы аңламый да кала. Мавыктыргыч серле тамаша күреп, кеше йә соклана, йә гаҗәпләнә. Фокусчының ялгышырга хакы юк. Ялгышса, көлкегә каласы көн кебек ачык. Кем дә кем яхшы фокусчы буласы килсә, манипуляция техникасын яхшылап өйрәнергә тиеш.

Без иң элек төрле вак әйберләр (реквизитлар) белән манипуляция ясарга өйрәнербез, аннары күз буу, аппаратлар белән чыгыш ясау булыр. Шулай ук микромагия, менталь магия, дәрвиш уеннары, сәхнә гипнозы, «күз буу, кара бүлмә» (кара театр) алымнары, серләре белән дә танышырбыз.

# Нәрсә соң ул манипуляция?

Кагыйдә

1. Манипуляциянең гадиен булсынмы, катлаулысынмы, әйбәтләп өйрәнмичә, беркемгә дә, хәтта өйдәге туган-тумачаларыгызга да күрсәтмәгез. Уңышсызлыкка очрап, көлкегә калуыгыз бар. Фокусчы өчен аннан да начары юк. Манипуляция, күз буу трюкларын күрсәткәндә, артист ялгышмаска тиеш.

2. Шул ук манипуляцияне, фокусны беркайчан да бер үк кешеләр каршында кабатлап күрсәтмәгез!

3. Мактанып, шаярган булып манипуляциянең, иллюзиянең серен бервакытта да ачмагыз. Тамашачы фокусчының серен белмәскә тиеш. Манипуляция бит әле ул фокус түгел, ә аның ярдәмчесе генә. Шуңа күрә сер ачылмасын, тамашачы гаҗәпләнерлек булсын.

4. Уңышсызлыклардан курыкмагыз, шаяртып төзәтеп җибәрсәң, аны тамашачылар сизми дә кала, «шулай кирәктер» дип кенә уйлый.

5. Яңа трюклар уйлап табыгыз. Һәр чыгышыгыз бәйрәмгә әйләнсен. Сәхнәдә фокус күрсәтү җан азыгы булсын. Шул вакытта гына чын артист-күз буучы (фокусчы) булырсыз. Тамашачыларга һәрвакытта рәхмәтле булып баш иегез, тез чүгегез. Шул вакытта гына тамашачылар сезне яратырлар, хөрмәт итәрләр.


## Тәңкәләр белән манипуляция

Күнекмәләр ясау өчен, төрле зурлыктагы тәңкәләр кирәк. Совет чорындагы 1 сумлык, хәзерге 5 сумлык тәңкәләр кулай. Алар залдагы тамашачыга яхшы күренәчәк. Күнегү өчен лимонад, сыра шешәләренең сырлы калай капкачлары бик әйбәт. Тәңкәләр, бөкеләр белән эшләгәндә, пальмировка (франц. *кучеру*), ягъни сиздермичә тәңкәне ачып уч төбендә тоту, уч төбенә кысу алымын яхшы итеп үзләштерергә кирәк.

Тәңкәне сул кулның уч төбенә куеп, «уңайлы урын» эзләгез, учның кайсы җирендә тәңкә яхшы кысылып тора ала, шунда туктагыз. Учның кайсы җире икәнен төгәл генә әйтеп булмый, чөнки төрле кешенең кулы төрлечә. Һәрбер өйрәнчек үзе, шул уңайлы урынны табып, репетицияләр уздырырга тиеш. Зур

күзге алдында күнегүләр уздыру үз-үзеңнең һәр хәрәкәтеңне күреп, ялгышларны бетерергә ярдәм итәр. Кул хәрәкәтен, гәүдә тотышын, мимиканы күзәтү уңайлы, файдалы булыр.


Пассировка тамашачыларның игътибарын җәлеп итү өчен кирәк. Янәсе, тәңкәне (шарны, бөкене) бер кулдан икенче кулга күчерәсез, ә ул вакытта тәңкә үз урынында, уч төбендә кала. (1 нче рәс.).



*1 нче рәсем*

Чыгыш вакытында бер үк хәрәкәтләрне кабатламагыз, тамашачыларның шикләнүе мөмкин. Шуның өчен төрлечә «пассировка» – күчерү хәрәкәтләрен үзләштерергә кирәк.

Иң элек тәңкәләр белән оста итеп пассировка ясарга өйрәнегез, аннан соң башка төрле әйберләргә күчәргә була. Өйрәнергә җиңел булсын өчен, пассировканы гадирәк ысуллардан башлыйбыз. Һәр кешенең биш бармагының да исемнәре бар: баш, имән, урта, атсыз һәм чәнти бармаклар.



*2 нче рәсем*


*1 нче ысул*. Уң кулыгыздагы тәңкәне имән бармак белән урта бармак арасына кыстырып (2 нче рәс.), баш бармак белән җиңел генә тотып, тәңкәне сул кулга күчерү хәрәкәте вакытында тәңкәне уч төбенә, үзегез «тапкан» җиргә куегыз. Ялган хәрәкәт ясап, янәсе, тәңкәне сул кулның учына саласыз (3 нче рәс.).



*3 нче рәсем*

Уң кул белән сул кул өстендә «сихри» хәрәкәтләр ясап, ике кулның да бармакларын, ачып, тамашачыларга күрсәтегез. Тәңкә юкка чыккан.

Сул кулның уч төбен (4 нче рәс.), уң кулның аркасын күрсәтеп, кулларның буш булуын, тәңкәнең юкка чыгуын күрсәтәсез. Ә чынлыкта тәңкә уң кулның уч төбенә кысылган була (4 нче рәс.).



*4 нче рәсем*

Хәзер инде «югалган тәңкә»не кайдан теләсәгез,